**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Карамалы авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Карамалы авылы №30 19 апрель 2016 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының "Карамалы авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе турындагы Нигезләмә хакында

Татарстан Республикасында коррупциягә каршы тору өлкәсендәге эшчәнлекне камилләштерү максатларында, «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, шулай ук «Россия Федерациясенең аерым дәүләт вазыйфаларын, федераль дәүләт хезмәте Вазыйфаларын биләүче затлар һәм башка затлар тарафыннан шәхси вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган кызыксыну, һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында"га карары нигезендә

Карамалы авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының "Карамалы авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин шәхси кызыксынуы барлыкка килү турындагы хәбәр итү тәртибе турында Нигезләмәне расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис А.Р. Ногманов

Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль
районының Карамалы
авыл җирлеге Советының
2016 елның 19 апрелендәге
30 номерлы карарына
кушымта

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының "Карамалы авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин шәхси кызыксынуы барлыкка килү турындагы хәбәр итү тәртибе турында Нигезләмә

1. Әлеге Нигезләмәдә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Карамалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе билгеләнә.

2. Муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар Россия Федерациясенең коррупциягә каршы көрәш турындагы законнары нигезендә вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында хәбәр итәргә, шулай ук мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу буенча чаралар күрергә тиеш.

Хәбәр вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында язма рәвештә рәсмиләштерелә (алга таба-хәбәрнамә).

3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Карамалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Карамалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгына 1 нче кушымтада каралган форма буенча төзелгән хәбәрнамә җибәрәләр.

4. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Карамалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы Татарстан Республикасы Азнакай район Советы Рәисенә 2 нче кушымтадагы форма буенча төзелгән хәбәрнамә җибәрә.

5. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Карамалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы адресына килгән хәбәрнамәләр карау өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә (алга таба Комиссия) тапшырыла.

Хәбәрнамәләрне алдан карау барышында Комиссия хәбәрнамәләр, аларда бәян ителгән хәлләр буенча аңлатмалар җибәргән затлардан билгеләнгән тәртиптә алырга һәм федераль дәүләт хакимияте органнарына, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм кызыксынган оешмаларга билгеләнгән тәртиптә запрослар җибәрергә хокуклы.

6. Мөрәҗәгатьләрне алдан карау нәтиҗәләре буенча аларның һәркайсына дәлилләнгән бәяләмә әзерләнә.

Хәбәрнамәләрне алдан карау барышында алынган хәбәрнамәләр, бәяләмәләр һәм башка материаллар комиссия утырышына тапшырыла, ул комиссиягә хәбәрнамәләр кергән көннән алып җиде эш көне эчендә үткәрелә.
Әгәр хәбәрнамә депутаттан-комиссия әгъзасыннан кергән булса, күрсәтелгән депутат хәбәрнамә комиссиясе каравында катнашмый һәм тавыш бирү хокукына ия түгел.
Әлеге Нигезләмәнең 5 пунктының икенче абзацында күрсәтелгән запрослар җибәрелгән очракта, хәбәрнамә, бәяләмә һәм башка материаллар Комиссиягә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Карамалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгына хәбәрнамәләр кергән көннән алып 45 көн эчендә тапшырыла. Күрсәтелгән срок озайтылырга мөмкин, ләкин ул 30 көннән дә артмаска тиеш.

7. Комиссия белдерүләрне карый һәм алар буенча карарлар кабул итә, аларны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Карамалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башлыгына җибәрә.

8. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Карамалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы комиссия тарафыннан мөрәҗәгатьләрне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә::
а) хәбәрнамә җибәргән зат вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликты булмавын танырга;
б) хәбәрнамә юллаган затның вазыйфаи бурычларын үтәгәндә шәхси кызыксынуы мәнфәгатьләр конфликтына китерә яисә китерергә мөмкин дип танырга;
в) хәбәрнамә юллаган зат тарафыннан мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм (яисә) җайга салу чаралары үтәлмәгәнлеген танырга.

9. Әлеге Нигезләмәнең 8 пунктындагы «б» пунктчасында каралган карар кабул ителгән очракта, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Карамалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы Россия Федерациясе законнары нигезендә мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу буенча чаралар күрә яисә чаралар күрүне тәэмин итә йә хәбәрнамә җибәргән Затка мондый чаралар күрергә тәкъдим итә.

10. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Карамалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Карамалы авыл җирлеге Советы Рәисе әлеге Нигезләмәнең 8 пунктындагы «в» пунктчасында каралган карар кабул ителгән очракта, муниципаль вазыйфаны биләүче затның вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату буенча чаралар күрә.

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының "Карамалы авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе турында Нигезләмәгә 1 нче кушымта

________________________

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Карамалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгына
Кемнән:
______________________________
(Ф.И.А.)

Вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин шәхси кызыксыну барлыкка килү турында хәбәрнамә

Вазифаи бурычларны башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерергә мөмкин шәхси кызыксынуым барлыкка килү турында хәбәр итәм (кирәклесенең астына сызарга).

Шәхси кызыксыну барлыкка килүгә нигез булып торган хәлләр: ____________________________________________________________.
_____________________________________________________________________

Шәхси кызыксыну йогынты ясый яки йогынты ясый ала торган вазифаи бурычлар: __________________________________________
_____________________________________________________________________

Мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау яки җайга салу буенча тәкъдим ителә торган чаралар: ________________________________________________________________
_____________________________________________________________________

Әлеге белдерүне караганда Законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча Комиссия утырышында шәхсән катнашырга ниятлим (ниятләмим) (кирәклесен ассызыкларга).

«___»_______________20__ел. __________________ _____________________
(хәбәрнамә җибәрүче затның имзасы) (имза)

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының "Карамалы авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе турында Нигезләмәгә 2 нче кушымта

________________________

Татарстан Республикасы Азнакай районы Советы рәисенә
кемнән:
____________________________
(Ф.И.А.)

Вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин шәхси кызыксыну барлыкка килү турында хәбәрнамә

Вазифаи бурычларны башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерергә мөмкин шәхси кызыксынуым барлыкка килү турында хәбәр итәм (кирәклесенең астына сызарга).

Шәхси кызыксыну барлыкка килүгә нигез булып торган хәлләр: _________________________________________________________.

____________________________________________________________________

Шәхси кызыксыну йогынты ясый яки йогынты ясый ала торган вазифаи бурычлар: ________________________________________

____________________________________________________________________

Мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау яки җайга салу буенча тәкъдим ителә торган чаралар: ______________________________________________________________

____________________________________________________________________

Әлеге белдерүне караганда Законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча Комиссия утырышында шәхсән катнашырга ниятлим (ниятләмим) (кирәклесен ассызыкларга).

«__»____________ 20__ ел _________________________

хәбәр итүне җибәрүче затның имзасы (имза)